СОВЕТ БЕЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКСУБАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БЕЛОВКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

03.08.2026 ел Яңа Үзи №22

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 19.10.2015 ел, №6 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 28.11.2025 N 425-ФЗ Федераль законы, Аксубай муниципаль районы «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советы КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге Советы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 19.10.2015 ел, №6 карарына түбәндәге үзгәрешләне кертергә (09.07.2018ел №61, 26.11.2018 ел №75, 13.12.2019 ел №109, 25.09.2023 ел №66, 13.11.2024 ел №92; 21.01.2026 ел №13 Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка Советы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып):

1.1 . 2 статьяның 1 пункты: һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан гаражларга һәм машина урыннарына карата 0,1 ставкасын 0,3 кә алмаштырырга.;

1.2. 2 статьяның 2 пунктында фатирлар, бүлмәләргә карата 0,2 ставкасын 0,3 кә алмаштырырга:;

2. Әлеге карар 2027 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм закон тарафыннан билгеләнгән вакытта Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru , хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Беловка авыл җирлеге башлыгы И. Р. Мәхмүтов